**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУЕМБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

от «05» сентябрь 2022 года № 22

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Туембаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2022 елның 16 сентябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 16 сентябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 16 сентябренә 14 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"- Туембаш мәдәният йортына тузан суырткыч сатып алу»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы: И. Ф.Гарипов